# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об Уполномоченном по правам человека в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
10 июня 2015 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 марта 2000 года № 95 «Об Уполномоченном по правам человека в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 9 августа 2003 года № 32-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 8 (I часть); 2013, № 2 (I часть); 2014, № 6 (II часть) следующие изменения:

1) в статье 1 слова «усиления гарантий государственной защиты прав и свобод человека и гражданина, содействия их соблюдению и уважению государственными органами, органами местного самоуправления и должностными лицами» заменить словами «обеспечения дополнительных гарантий государственной защиты прав, свобод и законных интересов человека и гражданина, а также для ее осуществления»;

2) в статье 3 слова «и неподотчетен каким-либо государственным органам, органам местного самоуправления и должностным лицам» заменить словами «от каких-либо государственных органов, органов местного самоуправления и должностных лиц»;

3) в наименовании главы II слова «и освобождения от должности» исключить;

4) статью 4 дополнить предложением следующего содержания: «До рассмотрения кандидатуры на должность Уполномоченного Государственный Совет Рес-

публики Татарстан согласовывает ее с Уполномоченным по правам человека в Российской Федерации.»;

5) в статье 6 слова «не моложе 35 лет» заменить словами «не моложе 30 лет, обладающее безупречной репутацией»;

6) в части 1 статьи 7 слова «права и свободы» заменить словами «права, свободы и законные интересы»;

7) в статье 8:

а) часть 1 дополнить предложением следующего содержания: «Уполномоченный, срок полномочий которого истек, продолжает исполнять обязанности до вступления в должность вновь избранного Уполномоченного.»;

б) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Одно и то же лицо не может быть избрано на должность Уполномоченного более чем на два срока подряд.»;

8) статью 11 изложить в следующей редакции:

«Статья 11. **Требования, ограничения и запреты для Уполномоченного**

1. Уполномоченный не может иметь гражданство иностранного государства либо вид на жительство или иной документ, подтверждающий право на постоянное проживание гражданина Российской Федерации на территории иностранного государства.

2. Уполномоченный не может быть одновременно депутатом Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации, членом Совета Федерации Федерального Собрания Российской Федерации или депутатом Государственного Совета Республики Татарстан, депутатом законодательного (представительного) органа государственной власти субъекта Российской Федерации, замещать государственные должности Российской Федерации, иные государственные должности Республики Татарстан, государственные должности субъекта Российской Федерации, муниципальные должности, должности государственной и муниципальной службы, заниматься другой оплачиваемой или неоплачиваемой деятельностью, кроме преподавательской, научной и иной творческой деятельности. При этом преподавательская, научная и иная творческая деятельность не может финансироваться исключительно за счет средств иностранных государств, международных и иностранных организаций, иностранных граждан и лиц без гражданства, если иное не предусмотрено международным договором Российской Федерации или законодательством Российской Федерации.

3. Уполномоченный не вправе быть членом политической партии или иного общественного объединения, преследующего политические цели.

4. Уполномоченный обязан соблюдать требования, ограничения и запреты, установленные федеральными законами и настоящим Законом.

5. Уполномоченный обязан прекратить деятельность, несовместимую с его статусом, не позднее 14 дней со дня вступления в должность, а также приостановить членство в политической партии на период осуществления своих полномочий. В случае, если в течение указанного срока Уполномоченный не выполнит установленные требования, его полномочия прекращаются досрочно.»;

9) статью 12 изложить в следующей редакции:

«Статья 12. **Досрочное прекращение полномочий Уполномоченного**

1. Полномочия Уполномоченного прекращаются досрочно в случае:

1) его смерти;

2) подачи им письменного заявления о сложении полномочий;

3) его неспособности по состоянию здоровья, установленной в соответствии с медицинским заключением, или по иным причинам в течение длительного времени (не менее четырех месяцев) исполнять свои обязанности;

4) признания его судом недееспособным, ограниченно дееспособным, безвестно отсутствующим или объявления его умершим;

5) вступления в отношении его в законную силу обвинительного приговора суда;

6) его выезда за пределы Республики Татарстан на постоянное место жительства;

7) утраты им гражданства Российской Федерации;

8) утраты доверия в случаях, предусмотренных статьей $13^1$ Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции»;

9) несоблюдения им требований, ограничений и запретов, установленных федеральными законами и настоящим Законом.

2. Решение о досрочном прекращении полномочий Уполномоченного принимается Государственным Советом Республики Татарстан большинством голосов от числа избранных депутатов Государственного Совета Республики Татарстан после консультаций с Уполномоченным по правам человека в Российской Федерации.

3. В случае досрочного прекращения полномочий Уполномоченного новый Уполномоченный должен быть избран Государственным Советом Республики Татарстан в течение двух месяцев со дня досрочного прекращения полномочий предыдущего Уполномоченного в порядке, установленном статьями 4 – 7 настоящего Закона.»;

10) в статье 13:

а) в части 1:

в абзаце первом слова «усиления гарантий государственной защиты прав и свобод» заменить словами «обеспечения дополнительных гарантий государственной защиты прав, свобод и законных интересов»;

в пункте 5 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

б) в части 3 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

11) в статье 14:

а) в части 1:

в пункте 2 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

дополнить пунктом 7 следующего содержания:

«7) беседовать с осужденными и лицами, заключенными под стражу, наедине в условиях, позволяющих представителю администрации учреждения или органа, исполняющего наказания, или следственного изолятора видеть беседующих, но не слышать их.»;

б) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Уполномоченный по вопросам своей деятельности пользуется правом безотлагательного приема руководителями и другими должностными лицами органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, иных органов и организаций, наделенных федеральным законом отдельными государственными или иными публичными полномочиями, а также администрациями мест принудительного содержания.»;

12) в наименовании главы IV слова «усилению гарантий государственной защиты прав и свобод» заменить словами «обеспечению государственной защиты прав, свобод и законных интересов»;

13) часть 1 статьи 16 изложить в следующей редакции:

«1. В целях содействия восстановлению нарушенных прав и свобод человека и гражданина Уполномоченный рассматривает жалобы граждан Российской Федерации, иностранных граждан и лиц без гражданства, находящихся на территории Республики Татарстан (далее – заявители), на решения или действия (бездействие) территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, руководство деятельностью которых осуществляет Правительство Российской Федерации, а также организаций федерального подчинения, государственных органов Республики Татарстан, органов местного самоуправления, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, муниципальных служащих, руководителей и иных должностных лиц организаций независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности, нарушающие права и свободы человека и гражданина.»;

14) в пункте 2 части 1 статьи 18 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

15) статью 19 дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. При рассмотрении жалоб на решения или действия (бездействие) территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, руководство

деятельностью которых осуществляет Правительство Российской Федерации, а также организаций федерального подчинения Уполномоченный вправе:

1) беспрепятственно посещать указанные территориальные органы и организации;

2) запрашивать и получать от них сведения, документы и материалы, необходимые для рассмотрения жалоб;

3) получать объяснения должностных лиц и государственных служащих указанных территориальных органов, организаций по вопросам, подлежащим выяснению в ходе рассмотрения жалоб;

4) проводить самостоятельно или совместно с компетентными государственными органами, должностными лицами и государственными служащими проверку деятельности указанных территориальных органов и организаций и их должностных лиц.»;

16) в статье 29 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

17) в статье 30:

а) в части 1:

абзац первый после слов «органов местного самоуправления» дополнить словами «, организации независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности»;

в пункте 3 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов»;

б) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Территориальные органы федеральных органов исполнительной власти, руководство деятельностью которых осуществляет Правительство Российской Федерации, а также организации федерального подчинения, их должностные лица при рассмотрении жалоб на их решения или действия (бездействие) обязаны в соответствии федеральным законодательством:

1) беспрепятственно пропускать Уполномоченного для посещения указанных территориальных органов и организаций;

2) предоставлять по запросам Уполномоченного сведения, документы и материалы, необходимые для рассмотрения жалоб;

3) предоставлять по запросам Уполномоченного объяснения должностных лиц и государственных служащих указанных территориальных органов, организаций по вопросам, подлежащим выяснению в ходе рассмотрения жалоб.»;

18) в части 2 статьи 31 слова «сведения о частной жизни заявителя и иных лиц, ставшие ему известными в связи с исполнением своих полномочий, без их письменного согласия» заменить словами «ставшие ему известными в процессе рассмотрения жалобы сведения о частной жизни лица, подавшего жалобу, и других лиц без их письменного согласия»;

19) в статье 32 слова «прав и свобод» заменить словами «прав, свобод и законных интересов».

**Статья 2**

Положение части $1^{1}$ статьи 8 Закона Республики Татарстан от 3 марта 2000 года № 95 «Об Уполномоченном по правам человека в Республике Татарстан» (в редакции настоящего Закона) применяется без учета начавшегося до дня вступления в силу Федерального закона от 6 апреля 2015 года № 76-ФЗ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации в целях совершенствования деятельности уполномоченных по правам человека» срока, на который избиралось лицо, замещавшее на день вступления в силу указанного Федерального закона должность Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Временно исполняющий обязанности
Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
27 июня 2015 года
№ 42-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында” 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 9 августындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014 № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда “кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең дәүләт тарафыннан яклануы гарантияләрен көчәйтү, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм урындагы затлар тарафыннан аларның үтәлүенә һәм хөрмәт ителүенә булышлык күрсәтү” сүзләрен “кеше һәм граждан хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануына өстәмә гарантияләрне тәэмин итү, шулай ук аны гамәлгә ашыру” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда “бәйсез була һәм нинди дә булса дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм урындагы затларга хисап бирми” сүзләрен “нинди дә булса дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйсез була” сүзләренә алмаштырырга;

3) II бүлекнең исемендә “һәм аны урыныннан азат итү” сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны карар алдыннан Татарстан Республикасы Дәүләт

Советы аны Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерә.";

5) 6 статьяда "35 яшьтән яшьрәк булмаган" сүзләрен "30 яшьтән яшьрәк булмаган, репутациясенә тап төшмәгән" сүзләренә алмаштырырга;

6) 7 статьяның 1 өлешендә "хокукларын һәм ирекләрен" сүзләрен "хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен" сүзләренә алмаштырырга;

7) 8 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Вәкаләте срогы беткән Вәкаләтле вәкил үз йөкләмәләрен яңа сайлап куелган Вәкаләтле вәкил вазыйфага кергәнче үтәүне дәвам итә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Бер үк зат Вәкаләтле вәкил вазыйфасына рәттән ике сроктан артыкка сайлап куела алмый.";

8) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Вәкаләтле вәкилгә карата таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар**

1. Вәкаләтле вәкилнең чит дәүләт гражданлыгы йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булырга тиеш түгел.

2. Вәкаләтле вәкил бер үк вакытта Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты була алмый, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый, укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле яисә түләүсез эш белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлек өчен түләү, әгәр башкасы Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчаларына финансланырга тиеш түгел.

3. Вәкаләтле вәкил сәяси партия яисә сәяси максатларны күз алдында тотып эшли торган башка иҗтимагый берләшмә әгъзасы булырга хокуксыз.

4. Вәкаләтле вәкил федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

5. Вәкаләтле вәкил үзенең статусы белән бергә башкарыла алмаган эшчәнлекне вазыйфага кергәнче кимендә 14 көн алда туктатырга, шулай ук үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чорына сәяси партиядә әгъза булуын туктатып торырга бурычлы.

Вәкаләтле вәкил билгеләнгән таләпләрне күрсәтелгән вакыт дәвамында үтәмәсә, аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.";

9) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12 статья. **Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу**

1. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булса;

2) вәкаләтләрен үз өстеннән төшерү турында язма рәвештә гариза бирсә;

3) медицина бәяләмәсе нигезендә билгеләнгән сәламәтлеге торышы буенча яисә башка сәбәпләр аркасында озак вакыт дәвамында (кимендә дүрт ай) үз бурычларын үти алмаса;

4) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалануга чикле сәләтле, хәбәрсез юкка чыккан дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

6) Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китсә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын югалтса;

8) "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^1$ статьясында каралган очракларда ышанычны югалтса;

9) федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәсә.

2. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән киңәшләшкәннән соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан алынган күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Вәкаләтле вәкил аңа кадәрге Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң ике ай эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан әлеге Законның 4 – 7 статьяларында билгеләнгән тәртиптә сайланып куелырга тиеш.";

10) 13 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта "хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү" сүзләрен "хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануына өстәмә гарантияләрне тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта "хокукларын һәм ирекләрен" сүзләрен "хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен" сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә "хокукларын һәм ирекләрен" сүзләрен "хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен" сүзләренә алмаштырырга;

11) 14 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта “хокукларын һәм ирекләрен” сүзләрен “хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

“7) хөкем ителгәннәр һәм сак астына ябылган затлар белән икәүдән-икәү сөйләшергә, бу вакытта аларның әңгәмәләре җәза үтәтү учреждениесе яисә органы администрациясе яки тикшерү изоляторы вәкиленә ишетелмәслек, ләкин үзләре күренерлек шартлар тудырылган булырга тиеш.”;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлегендәге мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары, шулай ук мәҗбүри тоту урыннары администрацияләре тарафыннан кичектергесез кабул ителү хокукыннан файдалана.”;

12) IV бүлек исемендә “хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү” сүзләрен “хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануын тәэмин итү” сүзләренә алмаштырырга;

13) 16 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Кеше һәм гражданның бозылган хокукларын һәм ирекләрен торгызуга ярдәм итү максатларында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан (алга таба – гариза бирүчеләр) федераль башкарма хакимият органнарының эшчәнлеккә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган территориаль органнарының, шулай ук федераль буйсынудагы оешмаларның, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, оешмалар җитәкчеләренең һәм башка вазыйфаи затларның кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата бирелгән шикаятьләрне карый.”;

14) 18 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында “хокукларын һәм ирекләрен” сүзләрен “хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен” сүзләренә алмаштырырга;

15) 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Эшчәнлекләренә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук федераль буйсынудагы оешмалар карарларына яисә гамәлләренә (гамәл

кылмауларына) карата шикаятьләрне караганда Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) күрсәтелгән территориаль органнарга һәм оешмаларга тоткарлыксыз үтеп керергә;

2) алардан шикаятьләрне карау өчен кирәкле белешмәләрне, документларны һәм материалларны соратып алырга;

3) күрсәтелгән территориаль органнарның, оешмаларның вазыйфаи затларыннан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән шикаятьләрне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча аңлатмалар алырга;

4) күрсәтелгән территориаль органнарның, оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының эшчәнлегенә мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органнары, вазыйфаи затлар һәм дәүләт хезмәткәрләре белән берлектә тикшерүләр үткәрергә.";

16) 29 статьяда "хокукларын һәм ирекләрен" сүзләрен "хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен" сүзләренә алмаштырырга;

17) 30 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта "җирле үзидарә органнары" сүзләреннән соң ", оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмаларның," сүзләрен өстәргә;

3 пунктта "хокукларын һәм ирекләрен" сүзләрен "хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

"$1^1$. Эшчәнлекләренә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук федераль буйсынудагы оешмалар, аларның вазыйфаи затлары аларның карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр каралганда федераль законнар нигезендә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) күрсәтелгән территориаль органнарда һәм оешмаларда булып китү өчен Вәкаләтле вәкилне тоткарлыксыз кертергә;

2) шикаятьләрне карау өчен кирәкле белешмәләрне, документларны һәм материалларны Вәкаләтле вәкил соратып алуы буенча бирергә;

3) Вәкаләтле вәкил соратып алуы буенча, күрсәтелгән территориаль органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларыннан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән шикаятьләрне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә.";

18) 31 статьяның 2 өлешендә "мөрәҗәгать итүченең һәм башка затларның шәхси тормышы турында үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган белешмәләрен язма ризалыгыннан башка фаш итәргә хокуклы түгел" сүзләрен "шикаятьне карау барышында шикаять биргән затның һәм башка затларның шәхси тормышы турында аңа мәгълүм булган белешмәләрне әлеге затларның язма ризалыгыннан башка фаш итәргә хокуксыз" сүзләренә алмаштырырга;

19) 32 статьяда “хокукларын һәм ирекләрен” сүзләрен “хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында” 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы $1^1$ өлеше нигезләмәсе (әлеге Закон редакциясендә) “Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр башланган, күрсәтелгән Федераль закон үз көченә кергән көнгә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын биләп торган зат сайлап куелган срокны исәпкә алмыйча кулланыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 27 июне
№ 42-ТРЗ